***Батыршина Гүзәл Гомәровна***
Россия ислам институты, Казан

# ТАТАР ТЕЛЕНЕҢ БЕРЕНЧЕ АҢЛАТМАЛЫ СҮЗЛЕГЕ

*Статья посвящена анализу первого толкового словаря татарского языка, составленного выдающимся ученым, просветителем К. Насыри. В ней рассматриваются принципы построения и способы толкования лексем этого словаря. Определяется генетический состав словника, в котором отражена лексика татарского национального литературного языка XIX в.*

**Ключевые слова:** *толковый словарь, словник, татарский язык, лексические единицы, принципы толкования.*

*This article analyzes the first explanatory dictionary of the Tatar language, compiled by outstanding scientist and educator K.Nasyri. It examines the principles and methods of interpretation of the words of dictionary. It determines the genetic makeup of the glossary, which shows in the vocabulary of the Tatar national literary language of the XIX century.*

**Keywords:** *Explanatory dictionary, glossary, Tatar language, lexical units, principles of interpretation.*

Татар тел белемендә аңлатмалы сүзлекләр төзү эше XIX гасырның икенче яртысына туры килә. Бу – күренекле галим, мәгърифәтче Каюм Насыйри исеме белән бәйле. Дөрес, 1829 елда ук Казан университеты профессоры Ф.И. Эрдман инициативасы белән, татар теленең тулы сүзлеген бастыру өчен, проект төзелә [Рахим, 1930: 3]. Анда татар сүзләренең мәгънәләрен ачыклау белән бергә, аларның русча һәм латинча тәрҗемәләрен бирү дә күздә тотыла. Әмма татар теленең аңлатмалы сүзлеген төзү эше тормышка ашмый кала. Шулай итеп, «татар тел белемендә генә түгел, гомумән, төрки тел белемендә беренче аңлатмалы сүзлек» [Зәкиев, 1978: 76; Миңнуллин, 1999: 124] Каюм Насыйриның «Ләһҗәи татари» сүзлеге була.

«Ләһҗәи татари» – ‘татар сүзлеге’ дигән төшенчәне белдерә. Ул – ике томлык хезмәт. Беренче томы – 1895, ә икенче томы 1896 нчы елларда Казан университеты типо-литографиясендә басылган. Лөгатьлеккә ун мең ярым чамасы берәмлек алынган.

Сүзлекнең төзелеше, лексик берәмлекләрне аңлату алымнары хәзерге чор лексикографик хезмәтләр төзү принципларына якын тора. «Ләһҗәи татари» сүзлегенә төрле сүз төркемнәренә караган берәмлекләр алынган. Аларның лөгатьлеккә теркәлү тәртибе, нигездә, татар теленең аңлатмалы сүзлеге кагыйдәләренә туры килә. Аеруча исем, сыйфат, сан сүз төркемнәренең бирелеше уңышлы. Автор лөгатьлеккә, аерым лексик

берәмлекләр итеп, төрле аффикс һәм кисәкчәләрне дә урнаштырган. Мәсәлән: *-даш//-дәш – мөшәракәтне (уртаклыкны) ифадә кылыр, якдаш, авылдаш, исемдәш, атдаш*. Төрки телләрдә, шул исәптән татар телендә дә, *-лар* күпмәгънәле кушымча [Фаттахова, 2016: 161]. К. Насыйри аның төп мәгънәсен генә күрсәтә: *-лар – күблекне ифадә кылыр, балалар, атлар*. *-ча//-чә, -сыз//-сез, -гала//-гәлә*, *-гыл//-гел, -кай* һ.б.ның да мәгънәләре сүзлектә шул рәвешчә аңлатыла. Моннан күренгәнчә, К. Насыйри кушымчаларны да аерым лексик берәмлек итеп караган. Бу күренешне В. Хангилдин болай аңлата: «Автор үзенең грамматик концепциясендә сүзләрне өчкә бүлә һәм шуларның берсе итеп алган ‘хәреф’ төркеменә кушымчаларны да кертә [Хангилдин, 1948: 87].

Сүзләрнең күпчелегенә К. Насыйри грамматик характеристика бирә, ягъни кайсы сүз төркеменә караганлыгын, грамматик мәгънәсен искәртеп бара. Бу да – хәзерге көн сүзлекләр төзүдә кулланылган принцип.

«Ләһҗәи татари»да урын алган тел байлыгының төп өлешен гомумкулланыштагы (нейтраль) лексика тәшкил итә. Шулай ук К. Насыйри кайбер сүзләрнең аңлатмаларында аларның кулланылыш чикләрен, эмоциональ төсмерләрен дә билгеләп үтә, ягъни стилистик характеристика бирә. Икенче бер сүзләрнең аңлатмасында аларның халык телендә йөргән вариантлары күрсәтелә һәм *‘гавам истыйляхы’*, *‘гавамда’* (ягъни халык телендә) дигән берәмлекләр белән билгеләнә: *уйнаш итмәк – мәгъшукланмак, гавам истыйляхынча йөрмәк, ягъни зина*; язма телдә генә кулланылган сүзләрне дә искәртеп бара: *әфтаб – фарсыдыр, кояш мәгънәсендә, китапларда мөстәгъмәлдер* (кулланыладыр – Г.Б.) Автор шулай ук сүзлектә аерым бер төркем кешеләр сөйләмендә кулланылучы лексик берәмлекләрне, ягъни профессионализмнарны билгеләп үтә: *өем – диһканлар истыйляхы* (игенчеләр сүзе – Г.Б); *текмәк – нәҗҗарлар истыйляхында* (балта осталары телендә - Г.Б.) *бинаның тышыннан такта кадакламак*. Сүзлек авторы аерым бер сүзләрнең эмоциональ төсмерләренә дә басым ясый. Мәсәлән, **түгәрәк** сүзен ачыклаганда, әлеге сүзнең мактау урынында да кулланылуын ассызыклап, «*ни хәл, түгәрәгем, ни кирәк*» мисалын китерә. Шулай итеп, К. Насыйри татар теленең нечкә мәгънә төсмерләрен оста сиземләп эш итә. Теге я бу сүзнең стилистик яктан кулланылыш үзенчәлекләрен күрсәтә.

«Ләһҗәи татари»да сүзләрнең мәгънәләренә бирелгән аңлатмалар, аерым очракларны исәпкә алмаганда, һәрвакытта да иллюстратив материал белән ныгытып барыла. Алар, башлыча, жанлы сөйләмнән, халык авыз иҗаты (ягъни җыр, табышмак, мәкаль, әйтемнәр), сирәгрәк язма әдәбияттан алынган мисаллардан гыйбарәт. Мәгънәне ачыклауда тел-сурәтләү чаралары (чагыштыру, эпитет, метафора) кергән мисаллар, аеруча фразеологик әйтелмәләр әһәмиятле урын алып тора.

«Ләһҗәи татари» сүзлегендә лексик берәмлекләр төрле принциплар нигезендә аңлатыла. Сүзлекнең төп принцибы турында К. Насыйри хезмәтенең титул битендә үк: «Татар телендә мәүҗүд булган әлфаз (сүзләр) мөрадифләре (синонимнары – Г.Б.) белән тәфсир кыйлынды», – ди. Дөрестән дә, сүзлекне карап чыкканнан соң, синонимнар аша аңлатуның төп принцип икәне аңлашыла. Мәсәлән: *ызгыш – кычкырыш, тавыш, гауга; ямьләмәк – матурламак, гүзәл итмәк, ыспайламак*, *күркәмләмәк*; *могтәбәр – игътибарлы, хөрмәтле, гыйззәтле* һ.б. Моннан тыш «Ләһҗәи татари»да сүзләрне аңлатуда антонимик билгеләмә, тасвирлау алымы, энциклопедик билгеләмә бирү, катнаш аңлатма, башка сүзгә кайтару алымнары да кулланылган.

К. Насыйриның «Ләһҗәи татари» сүзлегендә XIX йөз татар әдәби теле чагылыш таба. Хезмәтнең төп өлешен, әлбәттә, татар сүзләре алып тора. Алар арасында борынгы төрки телдән үк килгән традицион элементлар да шактый. Традицион язма тел үзенчәлекләре аерым сүзләрнең фонетик төзелешендә күзәтелә. Мәсәлән: *агыз, агламак, агыраймак, угры, уйгатмак (йокыдан тормак), уйгаткучы (сәгатьләмә), баг, багыр, бугдай, сач, сачәк, сачу, сүзләмәк, сычкан, тагук, тугыш (туыш)* һ.б. Шул ук вакытта сүзлектә *авыз, авыраймак, бау, чәчәк, тавык* кебек татар теленә хас формалар да урын алган. Лөгатьлектә традицион төрки язма формалардан угыз-төрек элементлары да (*бән, элгәре, капу, көпәк*, *канча, каму, шеш, шимди, иксемәк, имәс*), чыгтай теле үзенчәлекләре дә чагылыш таба. Соңгыларын (чыгтай теле сүзләрен) К. Насыйри искәртеп бара, лөгатьлектәге кайбер сүзләрнең чыгтай телендә дә кулланылуын, әйтелеш һәм язылышын күрсәтә. Мисаллар: *ака-әкә* (чыгтай лөгатендә ‘бертуган’ – К. Н.). Безнең карашыбызча, К. Насыйри татар әдәби теленә чыгтай теле тәэсирен күргән һәм аңлы рәвештә бу берәмлекләрне үзенең сүзлегенә алган.

Язма телдән традицион рәвештә килгән сүзләр (*уйку, сач, каму, капу*, *иксемәк,* һ.б.) хәзерге татар әдәби телендә кулланылмыйлар. *Архаизмнар* арасында бүгенге көн күзлегеннән караганда гына түгел, инде XIX гасыр өчен дә искергән сүзләр шактый. Автор үзе дә «Ләһҗәи татари» сүзлегендә теге яки бу сүзнең искергән булуын ‘кадим лисаныбызда’, ‘кадим лөгатьтә’, ‘төрки кадимдә’ дигән пометалар ярдәмендә күрсәтеп бара. Мисаллар: *бетимәк* – үсмәк, *битик* – язу, мәктүб, хат (хәзерге татар әдәби телендәге *бөти* сүзе шушы тамырга карый); *буга* – үгез; *тугыш* – туыш, көн тугышы, мәшрик; *кулагуз* – дәлил; *ут* – үлән; *үкүш* – күп; *яран* – дустлар. «Ләһҗәи татари» лөгатьлегендә урын алган әлеге архаизмнар борынгы төрки истәлекләрдә үк теркәлгән. Кайберләре исә (бетег, капу, ут, яран) татар теленең диалектларында бүгенге көндә дә очрый.

«Ләһҗәи татари» лөгатьлегенең шактый өлешен алынмалар тәшкил итә. Алар арасында гарәп-фарсы теленнән кергән сүзләр зур урын алып тора: *әдәб, иҗтиһад, ихлас, баб, остаз, тәрбия, тәгзыйм, тәкрар, тәүбә, зат,*

*зирагать, зәмһәрир, рәхимле, рөхсәт, рогбәт, сәнәгать, шәхес, тавил, гаһәд, фәһем, лисан, мәслихәт, намус, важиб, вәгъдә* һ.б.

Сүзлектә рус теле һәм рус теле аша Европа телләреннән кергән сүзләрне дә очратабыз: *журнал, лак, лампа, лимон, лира* һ.б.

Шулай итеп, К. Насыйриның «Ләһҗәи татари» сүзлегендә XIX гасыр татар әдәби теле чагылыш тапкан. Биредә язма әдәби телгә хас булган традицион формалар, чыгтай теле берәмлекләре, төрек теле элементлары, гарәп-фарсы сүзләре урын алган. Сүзләрне аңлатканда К. Насыйри синонимик принципка өстенлек биргән. Шул рәвешчә автор татар теленең синонимик байлыгын күрсәтергә тырышкан, алар ярдәмендә сүзләрне кыска, оста һәм дөрес итеп аңлата алган.

**Литература**


1. Закиев, М.З., Сафиуллина, Ф.С. «Толковый словарь татарского языка» (рец.) / М.З. Закиев, Ф.С. Сафиуллина // Советская тюркология. – 1978. – № 2. – С. 77-80.
2. Миннуллин, Ф.Г. Из истории татарских словарей / Ф.Г. Миннуллин // Проблемы лексикологии и лексикографии татарского языка, вып. 4. – Казань, 1999. – С.122-125.
3. Рахим, А. Проект составления толкового словаря татарского языка 100 лет тому назад / А. Рахим. – Казань, 1930. – 19 с.
4. Хангилдин, В.Н. Каюм Насыйри һәм татар лексикографиясе / В.Н. Хангилдин // Каюм Насыйри – 1825-1945. – Казан, 1948. – Б. 78-91.
5. Фаттахова, Р.Ф. О фонетических и семантико-стилистических особенностях употребления аффикса *-лар* в тюркских языках / Р.Ф. Фаттахова, Л.М. Гиниятуллина, С.Х. Айдарова // Филологические науки. Вопросы теории и практики. – 2016. № 4-1 (58). – С. 158-161.



***Бәширова Илида Басыйровна***

ТР ФА нең Г.Ибраһимов ис. Тел, әдәбият һәм сәнгать институты, Казан


## ИДЕЛ БУЕ ТӨРКИСЕ-ИСКЕ ТАТАР ТЕЛЕНДӘ ЯЗМА НОРМА МӘСЬӘЛӘСЕНӘ КАРАТА


*В статье рассматриваются особенности развития нормы старотатарского литературного языка, которая продолжала традиции общетюркского письменного языка на основе применения арабского алфавита и нашла отражение в различных жанро-стилевых произведениях, созданных в эпоху Волжской Булгарии, Золотой Орды, Казанского ханства и Российского государства (середины XIV в. в Поволжском регионе).*



**Ключевые слова:** *тюркский язык, старотатарский язык, арабская графика*, *огузо-турецкие слова и словоформы, разговорный язык, письменный литературный язык, норма и вариативность.*